| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2019 г. Бавлы № 121

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне
хәл итү буенча җирле үзидарә органнары
вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә
торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу
максатларында «Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы
бюджетына субсидияләр бирү
турында килешүләр төзү тәртибе хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү турында килешүләр төзү тәртибен расларга (1нче кушымта).

2. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү турындагы килешү формасын расларга (2нче кушымта).

3. Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Баулы шәһәре» муниципаль берщмлеге башкарма комитетына йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин

1нче кушымта

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча
җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә
торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында «Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына
субсидияләр бирү турында килешүләр төзү
тәртибе

1. Әлеге тәртип җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү турында килешүләр (алга таба - килешү) төзүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Килешүдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидияне күчерү һәм тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидияләр бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнар турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

Килешү, аңа үзгәрешләр кертүне һәм аны өзүне күздә тоткан өстәмә килешүләр билгеләнгән формалар нигезендә төзелә.

Килешү проектын «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты әзерли. Килешү проекты «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан Баулы муниципаль районы башкарма комитетына җибәрелә. Килешү «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Баулы муниципаль районы башкарма комитеты, субсидия алу өчен «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән вакыт эчендә, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

- «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирүгә гариза;

- акчаларга ихтыяҗны раслаучы документлар (шартнамәләр, контрактлар, башкарылган эшләр актлары).

2. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына субсидияләр шушы тәртипкә кушымтадагы форма буенча килешүләр төзү шарты белән бирелә.

Баулы муниципаль районы бюджетына субсидияләр Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль органнарының касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган счетларына күчерелә.

Әлеге бюджетара трансфертлар килешү төзелгән вакытка кадәр җыелма бюджет язмасы һәм касса планы нигезендә бирелә.

Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

Субсидияләр бирү елыннан соң килгән елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидия калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Закон нигезендә максатчан файдалануны «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.

2нче кушымта

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килгән чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү турында______ номерлы КИЛЕШҮ

«__» ___________ 2019 ел

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты исеменнән гамәлдәге Нигезләмә нигезендә эш итүче җитәкче _________________________ һәм гамәлдәге __________________________нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирлеге Башкарма комитет җитәкчесе ____________________________________________________________,

(алга таба "яклар" дип аталачак) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү тәртибе нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр.

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге килешүнең предметы – Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына субсидия бирү тора (алга таба - Субсидия).

1.2. Баулы муниципаль районына субсидия түбәндәге чараларга бирелә: ____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

(субсидия бирелә торган чаралар исемлеген күрсәтергә)

2. Субсидия бирү һәм күчерү тәртибе һәм шартлары

2.1. Субсидия “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлегенең __________ елга һәм 20_ - 20___ еллар план чорына бюджет турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

2.2. “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидияләрнең гомуми күләме 20___ елда ______________(_________________________) сум

(сумма сүзләр белән языла)

2.3. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитетына субсидия күчерү Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органының җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачык счетына килешүгә кул куелганнан соң 10 эш көне эчендә күчерелә.

3. Якларның үзара хезмәттәшлеге

3.1. “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бурычлы:

3.1.1. Район башкарма комитеты әлеге Килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү шартларын үтәгәндә, район бюджетына субсидияләр бирүне тәэмин итәргә;

3.1.2. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тотарга;

3.1.3. Акчаларның максатчан тотылуын раслаучы документларны тикшерүне тормышка ашырырга;

3.1.4. Әлеге килешүнең 3.4.1. п. Нигезендәге Башкарма комитет мөрәҗәгатен кабул иткән көннән алып 30 эш көне эчендә әлеге Килешүнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләр буенча район башкарма комитетына аңлатмалар җибәрергә.

3.2. “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты хокуклы:

3.2.1. Фактта башкарылган эш күләмнәрен (күрсәтелгән хезмәтләр, куелган товарлар), әлеге Килешү кысаларында бүлеп бирелгән акчаларны дөрес куллануны сайлап тикшерергә;

3.2.2. Субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, районнан Субсидияне кире кайтаруны таләп итәргә.

3.3. Район башкарма комитеты түбәндәгеләрне бурычлы:

3.3.1. Субсидияләрне максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

3.3.2. Эшләрне ______________________ кадәр башкарырга;

(көне, ае, елы)

3.3.3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга район бюджетына бирелгән субсидияләрдән файдалану турында хисап тапшырырга;

3.3.4. Соратып алу буенча, район тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартларның, максатларның һәм тәртипләрнең үтәлешен контрольдә тоту өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар тапшырырга;

3.4. Баулы муниципаль районы башкарма комитеты хокуклы:

3.4.1. Әлеге килешүнең үтәлешенә бәйле аңлатма алу өчен мөрәҗәгать итәргә.

## 4. Субсидияләр бирү шартларын бозганда аны һәм Субсидиянең файдаланылмаган калдыгын кире кайтару тәртибе

4.1. Субсидияне кире кайтару, аны бирү шартлары бозылган очракта, түбәндәге тәртиптә башкарыла.

Бүлеп бирелгән бюджет акчаларын кире кайтару кирәклеге турында боерык чыгарылган көннән алып биш эш көне эчендә районга тиешле язма хәбәрнамә җибәрелә. “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетыннан язма хәбәр алынганнан соң биш эш көне эчендә район акчаны кире кайтарырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны билгеләнгән срокта ирекле кире кайтарудан баш тартканда, әлеге акчалар суд тәртибендә эзләтеп алыналар.

4.2. Хисап елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына алынмаган Субсидия калдыгын кире кайтару түбәндәге тәртиптә башкарыла.

Район тарафыннан Субсидия калдыгы агымдагы финанс елының беренче ун эш көне дәвамында “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә кире кайтарыла.

Ихтыяҗы расланган Субсидия акчалары агымдагы финанс елында Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә шул ук максатларга район бюджетына кире кайтарылырга мөмкин.

## 5. Субсидия максатчан файдалануны контрольдә тоту тәртибе

5.1. “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты субсидияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тота.

## 6. Килешүнең гамәлдә булу срогы

6.1. Әлеге Килешү яклар имзалаган вакытта үз көченә керә һәм яклар әлеге килешү буенча йөкләмәләрне тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Баулы муниципаль районы башкарма комитеты бүлеп бирелгән субсидияне максатчан файдалану өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## 8. Субсидияләрдән файдалану турында хисап бирү тәртибе

8.1. Баулы муниципаль районы әлеге Килешүнең 3.3.3 пункты нигезендә хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр кәгазьдә һәм электрон чыганакларда хисап бирә. Проектны гамәлгә ашыру срогы Килешү төзү елыннан соң килгән елда тәмамланса - проектны гамәлгә ашыру тәмамланганнан соң 1 айдан да артмаган вакыт эчендә.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Әлеге Килешүне үзгәртү яклар инициативасы буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге Килешүгә өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә, ул аның аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Әлеге Килешүдә каралмаган барлык мәсьәләләрдә яклар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына таяна.

9.3. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелгән, бер нөсхә Совет өчен, икенчесе - җирлек өчен.

## 10. Юридик адреслар

| | |
|---|---|
| “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты: | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты: |
| ______________________________________ | ___________________________________ |
| _____________________________________ | ___________________________________ |

## 11. Яклар имзалары

| | |
|---|---|
| “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты: | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты: |
| _______________/ ___________ | _______________/ _____________ |
| М.У. (Ф.И.О.) | М.У. (Ф.И.О.) |
| «__»________ 20___ел. | «__»_________20 ___ел. |

_____номерлы ____________ Килешү нигезендә финанслау чыганагы субсидияләр булган чыгымнар турында хисап,
20____ елның «___»__________

Алучы атамасы: ______________________________

Үл. берәмлеге: сум (төгәллеге унлы билгегә кадәр)

| Күрсәткеч атамасы | Сумма |
|---|---|
| Ел башына калдык, барлыгы | |
| шул исәптән:<br>ихтыяҗы расланган | |
| Муниципаль район бюджетына кире кайтарылырга тиешле | |
| Барлыгы акча керде | |
| Чыгымнар буенча түләүләр, барлыгы | |
| шул исәптән муниципаль район бюджетыннан да | |
| Муниципаль район бюджетына кайтарылды, барлыгы: | |
| шул исәптән: максатчан билгеләнеш буенча сарыф ителмәгәннәре | |
| Хисап чоры ахырына файдаланылмаган акчалар, барлыгы: | |
| шул исәптән: шул ук максатларга юнәлдерү таләп ителә | |
| Кире кайтарылырга тиеш | |

Башкаручы _________________ ____________________ ____________________
(вазыйфа) имза (имза расшифровкасы)

Баулы муниципаль районы
Финанс-бюджет палатасы
җитәкчесе

______________ ___________________
имза имза расшифровкасы

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

______________ ___________________
имза имза расшифровкасы